ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

29.08.2017 г. Казань № 111-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 11.01.2017 № 004-од боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге № 63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча административ регламентын раслау хакында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 11.01.2017 № 004-од боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт вазыйфасы түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2002, № 1 (I өлеш) ст. 1, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Мәдәни кыйммәтләрне чыгару һәм кертү турында» 1993 елның 15 апрелендәге № 4804-1 Россия Федерациясе Законы белән («Российская газета» 1993 елның 15 мае, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) һәм дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге № 184-ФЗ Федераль закон белән (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 1999, № 42, ст. 5005, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон белән (алга таба –№ 131-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2003, № 40 ст. 3822, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге №125-ФЗ Федераль закон белән (алга таба – № 125-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2004, № 43 ст. 4169, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгать итүләре тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль закон белән (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2006, № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон белән (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2008, № 52 (I өлеш) ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Мәдәни кыйммәтләрне чыгаруга экспертиза уздыру һәм аны тикшереп тору турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2001 елның 27 апрелендәге № 322 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2001, № 19, ст. 1938, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Федераль башкарма хакимият органнарында эшләр алып баруның «Федераль башкарма хакимият органнарында эшләр алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 15 июнендәге № 477 карары белән расланган кагыйдәләре белән (алга таба – Федераль башкарма хакимият органнарында эшләр алып бару кагыйдәләре) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2009, № 25 ст. 3060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләрне уздыруның еллык планнарын әзерләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге № 489 карары белән расланган кагыйдәләре белән (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 489 карары белән расланган кагыйдәләр) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2010, № 28, ст. 3706, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28

апрелендәге № 415 карары белән (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2015, № 19, ст. 2825, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә шушы документлар һәм (яисә) мәгълүмат үз карамакларында булган дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалардан соратып алынучы документларның һәм (яисә) мәгълүматның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге № 323 күрсәтмәсе белән расланган исемлеге белән (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге № 323 карары белән (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2016, № 17, ст. 2418);

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вазыйфаи затлары эшчәнлегенә дәүләт контроле (күзәтчелеге) башкаруга вәкаләт тапшырылган дәүләт органнары тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вазыйфаи затларына тикшерүләр уздыруның еллык планнары проектларын әзерләү, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вазыйфаи затларын планнан тыш тикшерүләрне килештерүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 31 октябрендәге № 1106 карары белән расланган кагыйдәләре белән (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 1106 карары белән расланган кагыйдәләр) (Хокук мәгълүматның рәсми Интернет-порталы (pravo.gov.ru), 2016, 2 ноябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201611020015);

«Мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамау турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата каршылыклар белдерү һәм аларны карау кагыйдәләре, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге № 166 карары белән (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 166 карары) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2017, № 8, ст. 1239);

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә шушы документлар һәм (яисә) мәгълүмат үз карамакларында булган дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалардан соратып алынучы документларның һәм (яисә) мәгълүматның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге № 724-р күрсәтмәсе белән расланган исемлеге белән (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 724-р күрсәтмәсе белән расланган исемлек) (хокукый мәгълүматның рәсми Интернет-порталы (pravo.gov.ru),

2016, 22 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201604220035, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру хакында Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының 2009 елның 27 мартындагы № 93 боерыгы белән (алга таба – Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының № 93 боерыгы) («Законность», 2009, № 5, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) башкаруга вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеген тикшерүләрне уздыруның еллык планын формалаштыру һәм прокуратура органнарында килештерү буенча «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) башкаруга вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеген тикшерүләрне уздыруның еллык планын формалаштыру һәм прокуратура органнарында килештерү тәртибе турында» Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының 2014 елның 21 апрелендәге № 222 боерыгы белән расланган тәртибе (алга таба – Россия Генераль прокуратурасының № 222 боерыгы белән расланган тәртип) («Законность», 2014, № 7);

Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивлардагы, музейлардагы һәм китапханәләрдәге, Россия фәннәр академияләрендәге башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру буенча «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивлардагы, музейлардагы һәм китапханәләрдәге, Россия фәннәр академияләрендәге башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру буенча кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 18 гыйнварындагы № 19 боерыгы белән расланган кагыйдәләре белән (алга таба – 2007 елгы Кагыйдәләр) (Федераль башкарма хакимияте органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 20, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Фәнни-техник һәм җитештерү эшчәнлегендә барлыкка килә торган типовой архив документлары исемлеген раслау турында, саклау срокларын күрсәтеп» (алга таба – 2007 елгы исемлек) Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 31 июлендәге № 1182 боерыгы белән (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2007, № 46, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, Россия Фәннәр академиясе оешмаларында башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру буенча исәпкә алу һәм бүтән документларның формаларын раслау турында» Россия Федерациясе

Мәдәният һәм масакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 10 сентябрендәге № 1273 боерыгы белән (алга таба – № 1273 боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 20, 14.05.2007);

«Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль архивларында янгын куркынычсызлыгының махсус кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2009 елның 12 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән (Федераль башкарма хакимият органнары нормати актлары бюллетене, 2009, № 24);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге № 141 боерыгы белән (алга таба – Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) («Российская газета», 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге барышында барлыкка килүче идарәчел типовой архив документлары исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2010 елның 25 августындагы № 558 боерыгы белән расланган Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге барышында барлыкка килүче идарәчел типовой архив документлары исемлеге белән (алга таба – 2010 елгы исемлек); (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2010, № 38);

«Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда саклауны, туплауны исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» (алга таба – 2015 елгы кагыйдәләр) Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2015 елның 31 мартындагы № 526 боерыгы белән (хокукый мәгълүматның рәсми Интернет-порталы (pravo.gov.ru), 2015, 10 сентябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201509100001);

Россия Федерациясе Архив фонды документларын дәүләт исәбенә алуның Росархивның 1997 елның 11 мартындагы № 11 боерыгы белән расланган Регламенты белән (алга таба – 1997 елгы Регламент) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 1997, № 17);

«Федераль башкарма хакимияте органнарында эшләр алып бару инструкцияләрен әзерләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» Федераль архив агентлыгының 23.12.2009 № 76 боерыгы белән (www.archives.ru);

ВНИИДАД тарафыннан әзерләнгән, Росархив каршындагы Үзәк эксперт-тикшерү комиссиясе (ЦЭПК) белән килештерелгән «Дәүләт һәм муниципаль архивларны туплау чыганаклары – оешмаларны билгеләү» 2012

елның 30 октябрендәге методик рекомендацияләре белән (алга таба – 2012 елгы Методик рекомендацияләр) (www.archives.ru);

Законом Республики Татарстан от «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге № 63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законы) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU, 2017, 21 июль);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге № 63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – № 63-ТРЗ Законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2007, № 12, ст.1152, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендәге архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары составын һәм зурлыкларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.07.2008 № 499 карары белән (алга таба – № 499 карар); («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каралары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2008, № 30, ст.1159);

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.08.2016 № 541 карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә белән (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU, 2016, 10 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 21.09.2016 № 073-ОД боерыгы белән (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU, 2016, 21 октябрь) (алга таба – Дәүләт комитетының № 073-ОД боерыгы).»;

2.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.18. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары эшчәнлеген планнан тыш тикшерүләр Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән килештерү буенча гражданнардан, юридик затлардан кергән һәм дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарынан алынган гадәттән тыш хәлләр барлыкка килерлек итеп, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерерлек итеп яисә китерергә мөмкин булган, шулай ук гражданнар хокукларын массакүләм бозарлык итеп, Россия Федерациясе

законнарын бозулар фактлары турында мөрәҗәгатьләр буенча Дәүләт комитеты рәисе карары нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан уздырыла.

Планнан тыш тикшерүләр шулай ук прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтчелек кысаларында, шулай ук элегрәк мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә үтәлешен тикшереп тору максатларында Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушулары нигезендә һәм Россия Федерациясе Генераль прокуроры, Россия Федерациясе субъекты Прокуроры таләбе нигезендә, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында элек бирелгән күрсәтмә үтәлешен тикшереп тору максатларында уздырылырга мөмкин. Әлеге тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә генә уздырыла.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеген планнан тыш тикшерүләр Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән килештерү буенча гражданнардан, юридик затлардан кергән һәм дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан алынган гадәттән тыш хәлләр барлыкка килерлек итеп, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерерлек итеп яисә китерергә мөмкин булган, шулай ук гражданнар хокукларын массакүләм бозарлык итеп, Россия Федерациясе законнарын бозулар фактлары турында мөрәҗәгатьләр буенча Дәүләт комитеты рәисе карары нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан уздырыла.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеген планнан тыш тикшерүләр шулай ук могут также проводиться в соответствии с поручениями Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушулары нигезендә һәм и на основании требования Россия Федерациясе Генераль прокурорының, Россия Федерациясе субъекты прокурорының законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү турында прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча уздырылырга мөмкин.»;

2.26 пунктта «2.19 пунктның 2 пунктчасында» сүзләрен «2.19 пунктның 2 пунктчасындагы «а» һәм «б» сүзләренә алмаштырырга;

пункта 3.1 пунктның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица – Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата билдерелә торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| **Тикшереп тору объекты төре** | **Мәҗбүри таләпнең формулировкасы** | **Мәҗбүри таләпне урнаштыра торган норматив хокукый акт** |
|---|---|---|
| Әлеге Регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән | 1. Архив эшен финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 15 статьясы; 20.07.2017 |

| | | |
|---|---|---|
| объектлар, муниципаль архивлардан тыш | | № 63-ТРЗ ТР Законының 16 статьясы;<br>раздел 2 Правил 2015 елгы Кагыйдәләрнең 2 бүлеге;<br>№ 4804-1 РФ Законы |
| | 2. Оешмада эшләрнең номенклатураларын төзүгә һәм эшләрне формалаштыруга карата таләпләрне үтәү | 2015 елгы кагыйдәләрнең 4 нче бүлеге;<br>Федераль башкарма хакимияте органнарында эшләр алып бару кагыйдәләре;<br>2007 елгы исемлек;<br>2010 елгы исемлек |
| | 3. Оешмада эшләр документларының кыйммәтлелегенә экспертизага карата таләпләрне үтәү | 2015 елгы кагыйдәләрнең 4 нче бүлеге; |
| | 4. Архив документларын саклауга һәм исәпкә алуга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлеше, 17 статьясы, 19 статьясы, 23 статьясының 1 өлеше;<br>№ 644 ТР Законының 15 статьясы, 16 статьясы, 18 статьясы;<br>2015 елгы кагыйдәләрнең 2, 3, 5 нче бүлекләре; |
| | 5. Эшләрне әзерләүгә һәм оешма архивына тапшыруга карата таләпләрне үтәү | 2015 елгы кагыйдәләрнең 4, 5 нче бүлекләре; |
| | 6. Архив документларын файдалануга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 26 статьясындагы 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | | өлеше;<br>2015 елгы кагыйдәләрнең 5 нче бүлеге; |
| | 7. Эшләрне дәүләт архивына һәм муниципаль архивка даими саклау өчен сайлап алуга, әзерләүгә һәм тапшыруга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 22 статьясы;<br>20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законының 19 статьясы;<br>2015 елгы кагыйдәләрнең 6,7 нче бүлекләре; |
| Муниципаль архивлар | 8. Финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 15 статьясы;<br>20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законының 16 статьясы;<br>2007 елгы кагыйдәләрнең 2 нче бүлеге |
| | 9. Архив документларын саклауга һәм исәпкә алуга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 4 бүлеге;<br>20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законының 16 статьясы, 18 статьясы, 19 статьясы;<br>2007 елгы кагыйдәләрнең 2, 3 нче бүлекләре |
| | 10. Архив документларын файдалануга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 6 нчы бүлеге;<br>20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законының 22 статьясы;<br>2007 елгы кагыйдәләрнең 5 нче бүлеге |
| | 11. Муниципаль архивны туплауга карата таләпләрне үтәү | № 125-ФЗ Федераль законның 5 нче |

| | | |
|---|---|---|
| | | бүлеге;<br><br>2007 елгы кагыйдәләрнең 4 нче бүлеге |
| | 12. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге һәм муниципаль берәмлекләр территориясендәге архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә карата таләпләрне үтәү | № 63-ТРЗ ТР Законы;<br>20.07.2017 № 63-ТРЗ ТР Законының 16 статьясы, 22 статьясы;<br><br>№ 499 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамау турында кисәтүләрне төзү һәм җибәрү, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата каршылыклар белдерү һәм аларны карау кагыйдәләре, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 166 карары белән расланган.»;

4 нче бүлекнең 2 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2 нче таблица – Тикшерү уздыру максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| **Тикшереп тору объекты төре** | **Тикшерү уздыру өчен тапшырыла торган документ** | **Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт** |
|---|---|---|
| Әлеге Регламентның 1.4 пунктта күрсәтелгән объектлар, муниципаль архивлардан | Төп исәпкә алу документларында һәр язманың нигезе түбәндәгеләр була: | |
| | 1. Оешма архивына документлар кергәндә: | |
| | 1) структур бүлекчәләрнең даими, озак вакытка (10 елдан артыкка) | 2015 елгы кагыйдәләр (23, 24 |

| | | |
|---|---|---|
| тыш | сакланучы документларын һәм шәхси состав буенча документларны тапшыру описьлары | нче кушымталар) |
| | 2) оешма эшләренең җыелма номенклатурасы, структур бүлекчәнең башланган һәм тәмамланган эшләрнең саны турында рәсмиләштерелгән йомгак язмасы | 2015 елгы кагыйдәләр (25, 26 нчы кушымталар) |
| | 2. Оешма архивыннан документлар киткәндә: | |
| | 1) архив документларын саклауга кабул итү-тапшыру акты | 2015 елгы кагыйдәләр (20 нче кушымта) |
| | 2) сакламаска тиешле архив документларын юкка чыгаруга бүлеп бирү акты | 2015 елгы кагыйдәләр (21 нче кушымта) |
| | 3) документларны югалту турында акт | 2015 елгы кагыйдәләр (6 нчы кушымта) |
| | 4) архив документларын төзәтә алмаслык итеп бозулар турында акт | 2015 елгы кагыйдәләр (22 нче кушымта) |
| | 3. Архивның үзендәге эшләрне үтәү нәтиҗәләре буенча (җыелма описьлар төзү, шәхси документларны, архив коллекцияләрен фәнни тасвирлау, аеруча кыйммәте булган эшләрнең һәм документларның, иминият фондының һәм файдалану фондының описьларын төзү, берләшкән архив фондларын булдыру, документларның барлыгын һәм торышын тикшерүләр, исәпкә алу документларын үзара чагыштыру): | |
| | 1) даими, озак вакытка (10 елдан артыкка) сакланучы эшләрнең, шәхси состав буенча эшләрнең җыелма описе | 2015 елгы кагыйдәләр (14, 15, 16 нчы кушымта) |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) электрон эшләрнең, даими саклаудагы документларның описе, (10 елдан артыкка) саклanучы электрон эшләрнең, документларның описе | 2015 елгы кагыйдәләр (17, 18 нче кушымта) |
| | 3) фондның архив эшләре булуны һәм торышын тикшерү акты | 2015 елгы кагыйдәләр (3 нче кушымта) |
| | 4) исәпкә алу документларында техник хаталар турында акт | 2015 елгы кагыйдәләр (4 нче кушымта) |
| | 5) документларны табу турындагы акт (шушы фондка, архивка карамаган, исәпкә алынмаганнар) | 2015 елгы кагыйдәләр (5 нче кушымта) |
| | 4. Һәр стеллаж буенча топографик күрсәткеч карточкасы, топографик күрсәткеч карточкасы | 2015 елгы кагыйдәләр (1, 2 нче кушымталар) |
| | 5. Эшләрнең, документларның керүен һәм чыгуын исәпкә алу кенәгәсе | 2015 елгы кагыйдәләр (11 нче кушымта) |
| | 6. Описьлар реестры | 2015 елгы кагыйдәләр (19 нчы кушымта) |
| | 7. Бит – эшне таныклаучы | 2015 елгы кагыйдәләр (8 нче кушымта) |
| | 8. Дәүләт исәбенә алу регламенты | 1997 елгы Регламент |
| | 9. Фонд бите | 2015 елгы кагыйдәләр (13 нче кушымта) |
| | 10. Фондлар исемлеге | 2015 елгы кагыйдәләр (12 нче кушымта) |
| | 11. Оешма архивы документларын файдалану: | |
| | 1) социаль-хокукый гарызнамәләрне үтәү | |
| | 1. Архив белешмәсе | 2015 елгы кагыйдәләр (29 нчы кушымта) |
| | 2) вакытлыча файдалануга эшләрне бирү | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.1) эшләрне вакытлыча файдалануга бирү турында акт | 2015 елгы кагыйдәләр (10 нчы кушымта) |
| | 2.2) эшнең карта-алмаштыручысы | 2015 елгы кагыйдәләр (7 нче кушымта) |
| | 2.3) документларны файдалану бите | 2015 елгы кагыйдәләр (9 нчы кушымта) |
| | 12. Норматив хокукый актлар: Норматив хокукый актлар: оешманың нигезләмәсе яисә уставы; оешманың структурасы һәм аны үзгәртү; оешманың тарихи белешмәсе; эшләр алып бару буенча инструкция; эксперт комиссиясе төзү турында боерык, эксперт комиссиясе турындагы нигезләмә; архив турындагы нигезләмә (СНТД), архив өчен җаваплы зат билгеләү турындагы боерык (СНТД), архив өчен җаваплы вазыйфаи затының инструкциясе (СНТД); эшләр алып бару өчен җаваплы затны билгеләү турындагы боерык (СНТД), эшләр алып бару өчен җаваплы затның вазыйфаи инструкциясе (СНТД); оешманы төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында күрсәтмә актлар; архив җитәкчесен алмаштырганда кабул итү-тапшыру акты | 2015 елгы кагыйдәләр |
| Муниципаль архивлар | 13. Муниципаль архивка документлар кергәндә: | |
| | 1) архив документларын саклауга кабул итү-тапшыру акты | 2007 елгы кагыйдәләр (9 нчы кушымта) |
| | 14. Муниципаль архивтан архив документлары киткәндә: | |
| | 1) архив документларын милекчегә кайтару акты | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (1 нче кушымта) |
| | 2) сакламаска тиешле архив документларын юкка чыгару өчен | 2007 елгы кагыйдәләр (11 |

| | | |
|---|---|---|
| | бүлеп бирү акты | нче кушымта) |
| | 3) эзләү юллары тәмамланган документларның табылмавы турында акт | 2007 елгы кагыйдәләр (2 нче кушымта) |
| | 4) архив документларына төзәтелмәслек итеп зарар китерүләр турында акт | 2007 елгы кагыйдәләр (1 нче кушымта) |
| | 15. Архивның үзендәге эшләрне үтәү нәтиҗәләре буенча (җыелма описьлар төзү, шәхси документларны, архив коллекцияләрен фәнни тасвирлау, аеруча кыйммәте булган эшләрнең һәм документларның, иминият фондының һәм файдалану фондының описьларын төзү, берләшкән архив фондлары булдыру, документларның барлыгын һәм торышын тикшерүләр, исәпкә алу документларын үзара чагыштыру): | |
| | 1) табылмаган архив документларын исәпкә алу карточкасы | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (19 нчы кушымта) |
| | 2) эчке опись | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (11 нче кушымта) |
| | 3) шәхси архив документларын саклауга кабул итү акты | 2007 елгы кагыйдәләр (10 нчы кушымта) |
| | 4) архив документларының булу-булмавын һәм торышын тикшерү акты | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (9 нчы кушымта) |
| | 5) архив документларын тасвирлау, описьларны эшкәртү акты | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (7 нче кушымта) |
| | 6) даими саклау эшләре описе | 2007 елгы кагыйдәләр (7, 8 нче кушымталар) |

| | | |
|---|---|---|
| | 7) документларның төзәтелмәслек дәрәҗәдә бозылулары турында акт | 2007 елгы кагыйдәләр (1 нче кушымта) |
| | 8) архив документларының булу-булмавын һәм торышын тикшерү бите | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (27 нче кушымта) |
| | 9) исәпкә алу документларында техник хаталар турындагы акт | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (4 нче кушымта) |
| | 10) архив документларын табу турындагы акт | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (6 нчы кушымта) |
| | 16. Ярдәмче исәпкә алу документлары түбәндәгеләр була: фондларның хәрәкәте кенәгәләре һәм карточкалары, башка архивларга тапшырылган документларны исәпкә алу кенәгәләре, фондларны һәм юкка чыгару өчен бүлеп алынган документларны төрләре буенча исәпкә алу кенәгәләре һәм башкалар. | 2007 елгы кагыйдәләрнең 3.4.2 п. |
| | 17. Стеллаж саен топографик күрсәткеч карточкасы | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (15 нче кушымта) |
| | 18. Фонд саен топографик күрсәткеч карточкасы | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (16 нчы кушымта) |
| | 19. Документлар керүне һәм чыгуны исәпкә алу кенәгәсе (архивта һәр документ керүне һәм чыгуны исәпкә алу, шулай ук саклауга кергән һәм билгеле бер хронологик чорда чыккан документларның саны һәм составы, аларның торышы һәм тасвирламасы) | 2007 елгы кагыйдәләр (5 нче кушымта) |
| | 20. Эшләрнең, документларның реестры | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | | (14 нче кушымта) |
| | 21. Фонд эше | 2007 елгы кагыйдәләрнең 3.4.1. п. |
| | 22. Фондлар исемлеге | 2007 елгы кагыйдәләр (6 нчы кушымта) |
| | 23. Эшнең бите-раслаучысы | 2007 елгы кагыйдәләр (3 нче кушымта) |
| | 24. Архив саклагыч паспорты | 2007 елгы кагыйдәләрнең 3.4.1 п. |
| | 25. Муниципаль архив паспорты | 1997 елгы Регламент (1 нче кушымта) |
| | 26. Фонд бите | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (28 нче кушымта) |
| | 27. __________елның 01.01нә фондлардагы үзгәрешләр, аларның составы һәм күләме турында белешмәләр | 1997 елгы Регламент (3 нче кушымта) |
| | 28. Фотодокументлар описе, фотоальбомнар описе | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (37 нче кушымта) Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (36 нчы кушымта) |
| | 29. Шәхси состав буенча эшләр описе | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (38 нче кушымта) |
| | 30. Аудиовизуаль (кинофотовидео) документларны исәпкә алу бите | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (29 нчы кушымта) |
| | 31. Муниципаль архивны туплау | |
| | 1) учреждениеләр-туплау | 2007 елгы |

| | | |
|---|---|---|
| | чыганаклары исемлеге | кагыйдәләр, 2012 елгы Методик рекомендацияләр |
| | 2) граждannар-туплау чыганаклары исемлеге | 2007 елгы кагыйдәләрнең 4.2.2.п. |
| | 3) туплау чыганакларын оештыруга күзәтү эшләре | 2007 елгы кагыйдәләрнең 4.2.3.п. |
| | 4) муниципаль архивларга документларны кабул итү план-графигы | 2007 елгы кагыйдәләрнең 4.4.1.п. |
| | 5) ___ елның 01.12нә оешма архивы паспорты | 1997 елгы Регламент. (4 нче кушымта) |
| | 6) муниципаль архивларның ______ елның 1 декабренә оешмаларда – туплау чыганакларында документлар саклауның торышы турында белешмәләр | 1997 елгы Регламент. (6 нчы кушымта) |
| | 32. Документларны файдалану: | |
| | 1) социаль-хокукый гарызнәмәләрне үтәү: | |
| | 1.1) архив белешмәсе | 2007 елгы кагыйдәләр (13 нче кушымта) |
| | 1.2) архив өземтәсе | 2007 елгы Кагыйдәләрнең 5.9.п. |
| | 1.3) архив күчермәсе | 2007 елгы Кагыйдәләрнең 5.9.п. |
| | 1.4) кергән гарызнамәләрне теркәү журналы | 2007 елгы Кагыйдәләрнең 5.8.п. |
| | 2) эшләрне вакытлыча файдалануга бирү | |
| | 2.1) архив документларын бирүгә, фонд күчермәләрен файдалануга, эшләр описьларына, документларга заказ (таләп) | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (12 нче кушымта) |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.2) архив документларын вакытлыча файдалануга тапшыру турында акт | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (2 нче кушымта) |
| | 2.3) саклагычтан архив документларын, файдаланучының фонды күчермәләрен бирү кенәгәсе | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (24 нче кушымта) |
| | 2.4) карта-алмаштыручы | Россия Мәдәният министрлыгының № 1273 боерыгы (14 нче кушымта) |
| | 33. Норматив хокукый актлар: муниципаль архивның нигезләмәсе, җитәкчесенең, хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкциясе; муниципаль архив җитәкчесе алмашынганда кабул итү-тапшыру акты | 2007 елгы кагыйдәләр |

5.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җаваплы башкаручы Дәүләт комитеты карамагындагы документларда булган белешмәләр һәм юридик зат, индивидуаль эшкуар тапшырган документлардагы белешмәләр нигезендә түбәндәгеләрне башкара:

белешмәләрнең дөреслегенә бәяләү уздыра;

документлардагы белешмәләргә, юридик затның, индивидуаль эшкуарның эшчәнлеге предметының билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвенә бәяләү уздыра.

Кирәк чакта җаваплы башкаручы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р күрсәтмәсе белән расланган Исемлек нигезендә әлеге Регламентның 3 нче таблицасында күрсәтелгән мәгълүмат һәм документлар булган башка дәүләт ораганнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан пунктчасы таләпләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә документлар һәм (яисә) мәгълүмат, шул исәптән электрон рәвештә дә, соратып ала.

3 нче таблица – Соратып алына торган документлар һәм белешмәләр исемлеге

| **Гарызнамә җибәрелүче орган** | **Соратып алынучы документлар яисә белешмәләр** |
|---|---|
| Федераль салым хезмәте | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр |

| | |
|---|---|
| Федераль салым хезмәте | Индивидуаль затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр |

Документар тикшерү барышында юридик зат, индивидуаль эшкуар тапшырган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар йә шушы документлардагы белешмәләрнең Дәүләт комитетындагы белешмәләргә туры килмәве ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

юридик затка, индивидуаль эшкуарга бу хакта мәгълүматы булган һәм, хат алганнан соң ун эш көне эчендә язма рәвештә кирәкле аңлатмаларны таләп итеп, хат әзерли;

Дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) хатны имзалау өчен җибәрә;

имза салынганнан соң хатны юридик зат, индивидуаль эшкуар адресына тапшырылуы хакындагы хәбәрәмәсе белән заказлы почта юлламасы рәвешендә йә бүтән мөмкин булган юл белән (факсимиль элемтә, электрон почта аша, кулына тапшырып) алу турындагы тамгасы булган килеш җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү башланганнан соң биш эш көне эчендә яисә юридик заттан, индивидуаль эшкуардан аңлатмалар алганнан соң биш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: кирәкле аңлатмаларны язма рәвештә тапшыруны таләп итеп, юридик затка, индивидуаль эшкуарга җибәрелгән хат.»

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова